КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 18 май г.Казань № 402

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 25 ноябрь, 908 нче карары белән расланган Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәт күрсәтүләрнең индивидуаль программасын төзү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 25 ноябрь, 908 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 13 март, 151 нче; 2016 ел, 18 июнь, 414 нче; 2016 ел, 9 ноябрь, 834 нче; 2018 ел, 30 июль, 618 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәт күрсәтүләрнең индивидуаль программасын төзү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Социаль хезмәт күрсәтүдән файдалану турындагы мәсьәләне карап тикшерү өчен Татарстан Республикасында яшәү урыны (булу урыны) буенча теркәлгән гражданның яки аның законлы вәкиленең социаль хезмәтләр күрсәтү турында язма яки электрон рәвештә бирелгән гаризасы, йә аның мәнфәгатьләрендә башка гражданнарның, дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының, иҗтимагый берләшмәләрнең граждан яшәгән урын (булган урын) буенча Министрлыкның территориаль органына яки вәкаләтле оешмага мөрәҗәгате, йә ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында социаль хезмәтләр күрсәтү турында

тапшырылган гариза яки мөрәҗәгать нигез булып тора. Яшәү урыны (булу урыны) буенча теркәлү турындагы шарт яшәү урыны билгеле булмаган затларга, шулай ук законнар белән каралган очракларда балигъ булмаган затларга карата кагылмый.

Социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гариза Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча бирелә. Гаризада (мөрәҗәгатьтә) гражданның тормыш эшчәнлеге шартларын начарайта яки начарайта ала торган, социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗлык тудыра торган хәлләре турында, гаилә составы, гражданның аның белән бергә яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар белән туганлык элемтәләре, гражданның һәм аның гаилә әгъзаларының керемнәре, яшәү шартлары, социаль хезмәт күрсәтү формасы, файдаланырга теләгән социаль хезмәт күрсәтүләр һәм аларны күрсәтү дәвамлылыгы, социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүче турында мәгълүматлар күрсәтелә.

Социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза биргәндә граждан шәхесне раслый торган документын күрсәтә. Социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гариза законлы вәкил тарафыннан бирелгәндә яисә граждан мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре мөрәҗәгать иткәндә вәкилнең шәхесен һәм вәкаләтләрен раслый торган документлар күрсәтелә.

Гражданның үзе белән бергә яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар белән туганлык элемтәләре турында мәгълүматны раслау граждан тарафыннан күрсәтелгән белешмәләрне декларацияләү һәм аларны шәхесне таныклый торган документлар, шулай ук граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыклар белән раслау юлы белән гамәлгә ашырыла.

Граждан www.gosuslugi.ru адресы буенча урнашкан Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы аша, «шәхси кабинет»ны кулланып, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары һәм «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган электрон документ рәвешендә гариза җибәрергә хокуклы. Гаризага граждан гаризада бәян ителгән (күрсәтелгән) белешмәләрне үз эченә алган документларның күчермәләрен теркәргә хокуклы. Бу Тәртипнең 9 нчы пункты таблицасында күрсәтелгән, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә санап үтелгән документлар категориясенә карый торган документлар граждан тарафыннан, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары һәм «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланып (расланып), кәгазьдә яки электрон формада тапшырыла.»;

8 нче пунктта:

бишенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

алтынчы абзацта «бишенче – җиденче» сүзләреннән соң «6 нчы пунктындагы» сүзләрен өстәргә;

10 нчы пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Учреждениегә (вәкаләтле оешмага) социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза һәм документлар пакеты кергән көннән бер эш көне эчендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнардан, муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнардан, башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары ведомствосы буйсынуындагы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 1 өлешендә каралган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында (танудан баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәк булган, граждан (законлы вәкил), башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр тарафыннан тапшырылмаган (граждан мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракта) документлар һәм белешмәләр, шул исәптән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгыннан социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гаризада күрсәтелгән затларның яшәү урыны буенча теркәлүе турында мәгълүматлар соратып алына. Дәүләт яки муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы органнар (оешмалар) соратып алына торган мәгълүматларны сорау кергән көннән ике эш көне эчендә бирә;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　А.В.Песошин